-

**ГЛАВА ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru_

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның "28" сентябреннән №1

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2023 елның 11 октябренә 13.00 сәгатьтә, Горшково авыл мәдәният йортында (Кыр ур., 54) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү

«ДА» «ЮК».».

4. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә

соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылының Күларты урамы 35а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино
авыл җирлеге башлыгы

С.Ю.Питеркина